РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.02.2025 № 125-п

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 маендагы 605-п номерлы «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» карары белән расланган «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты таблицасында «Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | Программаны 2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 5.223, 570 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2023 ел-2 389,521 мең сум;<br>2024 ел-2 834,049 мең сум;<br>2025 ел-0,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы Карарына ярашлы рәвештә төгәлләштереләчәк. |

»;

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

Программаны 2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 5.223, 570 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2023 ел-2 389,521 мең сум;

2024 ел-2 834,049 мең сум;

2025 ел-0,000 мең сум.

Программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы Карарына ярашлы рәвештә төгәлләштереләчәк.».

1.3. Программаның 1 нче кушымтасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

ТР Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М. Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына 1 нче кушымта

## «2023-2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ДӘҮЛӘТ МИЛЛИ СӘЯСӘТЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ТӨП ЧАРАЛАРЫ

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1. Милли-мәдәни төркемнәр вәкилләренең үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештыру һәм аларның эшен оештыру | «Мәгариф идарәсе " МКУ, ЯЭСБ, ҮАКС | | - | - | - |
| 2. Дини һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек советы утырышларын үткәрүне тәэмин итү | БК | | - | - | - |
| 3. Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләрен берләштерү факторы булган тарихи даталарга багышланган чаралар әзерләү һәм оештыру | БК бүлекләре | | - | - | - |
| 4. Фәнни тикшеренүләр оештыру, Мәгариф һәм мәдәни проектлар әзерләү, ТР Массакүләм мәгълүмат чараларында ТРда яшәүче халыклар вәкилләрен берләштерү факторы булган тарихи даталарны киң яктыртуны тәэмин итү | БК бүлекләре | | - | - | - |
| 5. "Сабантуй", "Нәүрүз" халык бәйрәмнәрен үткәрү | ҮАКС, ҮКС, Спорт учреждениеләре | МБ | 2 022,500 | 2 540,049 | 0,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6. «Сабантуй» балалар бәйрәмнәрен үткәрү | «Мәгариф идарәсе " МКУ | МБ | 367,021 | 294,000 | 0,0 |
| 7. Бөтенхалык бәйрәмен оештыру Халыклар бердәмлеге көне 4 ноябрь | «Мәгариф идарәсе " МКУ, ЯЭСБ, ҮАКС, ҮКС | | - | - | - |
| 8. Программа чараларын мәгълүмати яктыртуны оештыру | ММЧ | | - | - | - |
| 9. Төрле милләт яшьләренең дуслыгын пропагандалау буенча теле-радио тапшырулар әзерләү | ММЧ | | - | - | - |
| **Барлыгы** | | | **2 389,521** | **2 834,049** | **0,0** |

**Кулланылган кыскартулар:**
БК-Саба муниципаль районы Башкарма комитеты;
ЯЭСБ-Саба муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге;
ҮАКС- Саба муниципаль районының үзәкләштерелгән авыл клуб системасы;
ҮКС - Саба муниципаль районының Үзәкләштерелгән китапханә системасы;
ММЧ - Саба муниципаль районы территориясендә эшләп килүче массакүләм мәгълүмат чаралары - «Тагмедиа» АҖ филиаллары «Саба таңнары "газетасы редакциясе һәм" Саба дулкыннары " телерадиокомпаниясе